

13нче сентябрьдә илебездә парикмахерлар конен бил-геләп vттек. «Кешегә матурлык оләшәсем килә», – ди Гvзәл Ростәм кызы Алимова. Тырыш һәм унган кыз ул, профессиясен ярата. Башкаларга охшамаган, нечкә кvнелле, тагын бер vзенчәлеге бар: телен, милләтен чын-чынлап ярата.
Анын белән аралашканда кайбер сорауларыма жавап алдым.
*- Үзен белэн таныштырыр иден?*
- Безнен гаилә матур гына, башкалар тосле яши. Әнием, Адилә Искак кызы, Саранскнын Бишенче номерлы («Резинотехника») республика клиник  дәваханәсендә шәфкать туташы-медсестра булып эшли, ә әтием - Ростәм Касим улы, ООО «Резинотехника» предприятиясендә слесарь булып хезмәт итә. Гаиләдә без ике кыз – Дания сенелем бар. 2003 елда Ләмберә районы Аксен урта мәктәбен тәмамлап, Саранск башкалабызнын 37нче училищесында парикмахерлар профессиясен vзләштердем. Һәм 2004 елдан алып универсал парикмахер буларак салонда кешеләргә матурлык оләшәм.       *- Телэсэ кем чэч кисvче булып китэ алмый бит, мона сэлэт кирэктер?*
- Сәләт тә кирәк. Аннары минем укытучыларым бик шәп иделәр; барысына да ойрәттеләр. Үземдә дә кызыксыну, тырышлык кочле булды. Башта куркытты. Аннары, эшемне кvреп, Саранскнын чәч кисv салоннарына чакырдылар. Эшем жайга салынды. Үз клиентларым барлыкка килде.
Эшемне яратам, яратмасан парикмахер булып эшләп булмый шул. Кешеләр мина матурлык очен килә. Ометләренә шик тешерергә ярамый.
*-Төрле кешелэр очрыйдыр, эйеме?*
- Була шундый кешеләр, энергиянне ашыйлар. Алардан сон хәлсезләнеп каласын. Мин кешегә прическа ясаганда фантазиягә нык бирелӛм, ботен кvнелемне биреп эшлим. Безнен эштә кvпмедер дәрәжәдә психолог та булырга кирәк. Кешеләрнен эч серләрен тынлыйм. Менә берсендә бер хатын килде мина. Үзгәрергә телим ди. Үзгәрттем мин аны. Яна образы хәтта vзенә дә бик ошап китте.
*– Бvген яшьлэр нинди прическа ярата?*

- Хатын-кызлар, яше-карты модадан чыкмый торган карены, торле озынлыкта киселә торган каскад, сессон, дебют...Ә ир-атлар классиканы бик тә ярата, спорт стилендә еш кистерәләр, милитари, сонгы вакытта кемнен чәчләре куе гранж стилен vз итәләр.
*- Укучыларга чәчләрне карау буенча берәр кинәш бир әле?*
- Буялган чәчләр очен, берvк, халык медицинасы куллана кvрмәгез, чәчегез яшел тоскә дә керергә момкин, андый чәчләргә бары профессиональ тәрбия кирәк. Майлы чәчләрне икешәр тапкыр юарга кинәш итәм. Ахырдан бальзам кулланыгыз, ул чәчләрне сынудан саклый.

**Н.Хәлил**